ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 593-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев һәм алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.Н. Шәфигуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 593-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 68-VII ДС

Проект Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.Н. Шәфигуллин,
Р.Р. Гайзатуллин, М.Һ. Галиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 7 өлеш өстәргә:
«7. Дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматны «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында билгеләнгән мәгълүматны яклау турындагы таләпләргә туры килми торган башка мәгълүмат системаларына тапшыру рөхсәт ителми.»;

2) 12 статьяның 3 өлешендә «федераль законнар» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе Президенты актлары» сүзләрен өстәргә;

2) 15 статьяның 2 өлешендә «системаларындагы» сүзләреннән соң «, дәүләт органнарының, дәүләт унитар предприятиеләренең, дәүләт учреждениеләренең башка мәгълүмат системаларындагы» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 8 августындагы 216-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Федераль закон нигезендә федераль башкарма хакимият органнары дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматны гына түгел, дәүләт органнарының, дәүләт унитар предприятиеләренең, дәүләт учреждениеләренең башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматны да яклау турында таләпләр билгели.

Шулай ук дәүләт мәгълүмат системаларыннан мәгълүматны «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында билгеләнгән мәгълүматны яклау турындагы таләпләргә туры килми торган башка мәгълүмат системаларына тапшыруга да тыю кертелә.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты тарафыннан «Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын эксплуатацияләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларында мәгълүматны яклауны тәэмин итү тәртибен регламентлаштыра торган үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.